ГЛАВА
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.04.2025 с.Старое Дрожжаное № 16.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибенә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 547-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының 2017 елның 01 декабрендәге 48 номерлы (14.02.2019 № 11, 25.07.2023 № 32, 13.10.2023 № 43, 28.05.2024 елның 13 номерлы редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2 бүлекнең 2.1 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Гражданның мөрәҗәгате (алга таба — мөрәҗәгать) — «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба - Бердәм портал), дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының башка мәгълүмат системасыннан йә дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының рәсми сайтыннан файдаланып, язма рәвештә яисң электрон документ рәвешендә дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфа затка гражданнарны идентификацияләүне һәм (яисә) аутентификацияләүне тәэмин итүче "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең (әгәр әлеге Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса), тәкъдим, гариза яисә шикаять, шулай ук гражданның дәүләт органына, җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгате;»;

**6 бүлеккә** түбәндәге эчтәлекле **6.3 пункт өстәргә:**

«6.3. Гражданнарның иминлеген тәэмин итү максатларында аларның оператив-эзләү эшчәнлеген яисә Россия Федерациясенең иминлеген тәэмин итүне гамәлгә ашыручы органнарга, күрсәтелгән органнарның вазыйфаи

затларына Эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, иминлекне тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, Тышкы разведка өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актлары белән мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә, дәүләт саклавы өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан мөрәҗәгатьләрне электрон документ рәвешендә җибәрүнең һәм мөрәҗәгатьләргә җаваплар, хәбәрнамәләр җибәрүнең махсус тәртибе билгеләнергә мөмкин.»;

**18 бүлекнең 6 абзацында** «күрсәтелгән электрон почта адресы буенча» сүзләрен «күрсәтелгән Бердәм порталда электрон почта адресы буенча йә шәхси кабинет адресы буенча» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы М.Р. Гафаров